Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№17 (68)

23 май 2013 ел

**• Вакыйгалар эзеннән**

22 апрель көнне **И.ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ** чираттагы **УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Беренче булып, Административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** контроль йөкләмәләрнең үтәлеше белән таныштырды. Бу уңайдан Кремль урамы 27 йорт адресы буенча урнашкан бинаны кулланылышка алу мәсьәләсе каралды. Аның мәйданы зур, бинаны нинди максаттан файдалану турында уйларга кирәк. Куркынычсызлык буенча да кайбер кимчелекләр бар. Универсиада авылында камералар тиешле дәрәҗәдә эшли, ә менә төп бина һәм уку йортының башка корпусларында хәл итәсе проблемалар бар. Бу мәсьәләгә ректор аеруча җаваплы карарга кушты. Уку йортының халыкара эшчәнлеге турында Тышкы элемтәләр буенча проректор **Л.ЛАТЫЙПОВ** институтлардан алынган мәгълүматлар буенча әзерләнгән хисап җиткерде. Соңгы өч ел эчендә чит илдән килеп укучы студентлар саны 54 процентка арткан. Барлыгы 47 халыкара проект тормышка ашырылган. Чит ил уку йортларыннан лекция укырга 30 галим чакырылган, моннан тыш безнең уку йортында 13 укытучы даими рәвештә эшли. «Югары квалификацияле фәнни кадрларны аттестацияләү системасын модернизацияләү концепциясе» проекты буенча Фәнни эшчәнлек буенча проректор **Д.НУРГАЛИЕВ** чыгыш ясады. Ахырдан янә өч мәсьәлә каралды. Алар компьютерларны янарту, Физика институтының атом-төш физикасы лабораториясен лицензияләштерү, КФУда нәшрият эшен үзгәртеп кору кирәклегенә бәйле иде.

• • • •

15-18 май көннәрендә Санкт-Петербург шәһәрендә узган Халыкара юридик форум барышында Казан федераль университетының юридик факультет студенты **С.АЛЕКСАНДРОВНЫ РОССИЯ ЮРИСТЛАР АССОЦИАЦИЯСЕНЕҢ АППАРАТ ҖИТӘКЧЕСЕ УРЫНБАСАРЫ** итеп билгеләүләре турында хәбәр иттеләр. Чара Россия Хөкүмәте Рәисе Д.Медведев һәм башка югары дәрәҗәле вәкилләр катнашында үтте.

• • • •

18 май көнне КФУ студенты **ДИНӘ ГАРИПОВА** Швециянең Мальмё шәһәрендә узган **«ЕВРОВИДЕНИЕ-2013»** халыкара җыр **БӘЙГЕСЕНДӘ БИШЕНЧЕ УРЫН ЯУЛАДЫ**. Татарстанның атказанган артисты 10 саны астында инглиз телендә «What if» җыры белән чыгыш ясады. (Бу хакта тулырак алдагы санда укый аласыз).

• • • •

20 май көнне Казан университетының Тарих музеенда, БДБ илләре һәм Россия югары уку йортларының яшь галимнәренә булышлык күрсәтү унаеннан, бишенче тапкыр **«ОПТЭК» КОМПАНИЯСЕНЕҢ ГРАНТЛАРЫН** тапшыру тантанасы булды. КФУдан «Биология» юнәлешендә Фундаменталь медицина һәм биология институтының генетика кафедрасы соискательләре В.Соловьева һәм И.Старостина, «Медицина» юнәлешендә шул ук институтның биохимия кафедрасы галимнәре Д.Сәйфуллина һәм А.Мартынованың проектлары югары бәяләнде.

• • • •

20 май көнне КФУда **«КАЗАН ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫ СТУДЕНТЛАРЫНЫҢ МИЛЛӘТАРА АҢЛАШУЫ, ТОЛЕРАНТЛЫГЫ ҺӘМ ГРАЖДАНЛЫК ТИНДӘШЛЕГЕ»** дип аталган түгәрәк өстәл үтте. Әлеге актуаль мәсьәләләр хакында Казан дәүләт милли тикшеренү технология университеты, Казан дәүләт энергетика университеты һәм КФУның чит ил студентлары сөйләште.

• • • •

Пусан милли университетында КФУ һәм Корея вузының Гуманитар фәннәр колледжы арасында студентлар алышу турындагы килешүгә кул куюны билгеләү йөзеннән, **ФОТОКҮРГӘЗМӘ АЧЫЛДЫ**. Килешү нигезендә һәр семестрда КФУның Кореяны өйрәнүче 2 студенты ПМУ белән алышу программасында катнаша ала. Алар вузда уку өчен, түләүдән азат ителәләр. Күргәзмәдә Казан университеты матбугат үзәге тәкъдим иткән студентларның уку, тору һәм ял итү шартларын тасвирлаган фотолар урын алган. Күргәзмә 18 июньгә кадәр эшләячәк.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотолары

# Кече университет зур канатлар куя!

**Динара МИННЕКАЕВА**, хәбәрче

21-22 май көннәрендә Кече университетта чыгарылыш кичәләре узды.

Уку йорты үз эшчәнлеген 1978-79 елларда башлап җибәрә. Аның төп максаты булып, Казан федераль университеты, аның эшчәнлеге белән таныштыру, укучыларны кызыксындырып, уку йортына җәлеп итү тора.

Биредә ел саен биш йөзләп укучы белем алып чыга. Университетта барлыгы алты факультет бар: физика-математика, астрономия, химия-биология, филология, җәмгыять фәннәре һәм тел мәктәбе. Укырга контроль эшләр һәм махсус башкарылган тест нәтиҗәләре ярдәмендә кабул итәләр. Конкурс зур, гадәттә, бер урынга 2-3 кеше туры килә. Дәресләр 1 октябрьдә башлана. 8-11 сыйныф укучылары атнасына ике-өч тапкыр Казан федераль университеты базасында эшли торган лабораторияләрдә, китапханәләрдә шөгыльләнәләр. Алар өчен махсус лекцияләр укыла, практик дәресләр, лаборатор эшләр, индивидуаль консультацияләр уздырыла. Белем дәрәҗәсен елга ике тапкыр кышкы һәм язгы сессияләр барышында зачет-имтиханнар ярдәмендә тикшерәләр. Ел саен курслар тәмамлана, яңа уку елыннан икенче программа буенча укый башлыйлар. Әлегә Кече университетка Казан мәктәпләре укучылары гына кабул ителә. Киләчәктә укуны дистанцион рәвештә алып бару һәм республика мәктәпләре белән хезмәттәшлек итү планлаштырыла.

Кече университетның психологик һәм профориентацион эшчәнлегенә дә басым ясыйсы килә. Яшь психолог мәктәбе (9-11 сыйныф укучылары) практик психология өлкәсендә яңа белем һәм тәҗрибәләр алу мөмкинлеге тудыра. Ул югары сыйныф укучыларына һөнәр сайлауда, үзенең шәхси потенциалын аңлатуда ярдәм итә. Шулай ук укучылар өчен онлайн тестлаштыруларда, төрле тренингларда катнашу, психологтан консультация алу мөмкинлеге бар. Чит телне тирәнтен һәм тиз арада өйрәнергә теләүчеләргә «Тел барьерын үтү» тренинглары эшли.

Шулай ук Кече университет төбәкара предмет олимпиадалары уздыра. Аларда Россия төбәкләреннән һәм БДБ илләреннән 9-11 сыйныф укучылары катнаша. Олимпиада төп предметлар буенча ике турда үтә.

Кече университет кысаларындагы «Квант» – җәйге профиль мәктәбе эшчәнлеген 1972 елда башлап җибәрә. Башта ул физик юнәлеш буенча гына эшли, ә 1973 елдан башлап, физика-математика юнәлешен ала. Ел саен ул үзенә республикадан һәм Россиянең төрле төбәкләреннән 200гә якын төрле олимпиада һәм конференция җиңүчеләрен кабул итә.

**Ахыры 2нче биттә.**

**• Белем баскычлары**

# Киләчәгебез – гуманитар фәннәр!

**Ләйсән ИСХАКОВА**, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

21 май көнне КФУда «Ad astra per aspera» дип аталган социомәдәни тикшеренүләр өлкәсендәге фәнни-тикшеренү эшләре конкурсына йомгак ясалды. Анда Татарстан югары уку йортларында укучы студент һәм аспирантлар катнашты.

Әлеге бәйге КФУның Җәмгыятьләрне модернизацияләү буенча чагыштырма эзләнүләр институты тарафыннан оештырылды. Быел беренче мәртәбә генә уздырыла торган бу конкурска республикабызның төрле югары уку йортларыннан һәм Фәннәр Академиясеннән барлыгы 30 эш кабул ителгән.

Чарада КФУның фәнни эшләр буенча проректоры Данис Нургалиев та катнашты. Ул гуманитар фәннәрнең бүгенге хәле, киләчәге хакында фикерләрен җиткерде. «Гуманитар фәннәр техника, физика, биология h.б фәннәр киселешендә яши. Киләчәк белем бирү системасы гуманитариягә корылачак», – дип белдерде ул чыгышында. Бәйгенең йомгаклау өлешендә Җәмгыятьләрне модернизацияләү буенча чагыштырма эзләнүләр институты хезмәткәрләре үзләренең эшләре, проектлары хакында мәгълүмат бирде.

**Ахыры 2нче биттә.**



Диана Поварова фотосы

● Белем баскычлары

# Киләчәгебез – гуманитар фәннәр!

**Башы 1нче биттә.**

Күптән түгел генә оешкан бу институт якын арада «Чагыштырма социаль анализ» магистр программасын тормышка ашырырга җыена. Ул хәзерге социаль күренешләрне анализлый һәм әһәмиятле социаль мәсьәләләрне чишү юлларын тәкъдим итә белә торган белгечләр әзерләүне максат итеп куя. Биредә студент һәм аспирантларга фәнни эшне язу, аны төзәтү, яклау серләрен ачалар.

«Ad astra per aspera» конкурсының нәтиҗәләренә килгәндә, алар түбәндәгедән гыйбарәт: студентлар арасында беренче урынга – **Руслан Митрофанов** (КФУның Тарих институты), ә аспирантлар арасында **Наталья Чернова** (ТР Фәннәр Академиясенең перспектив икътисади тикшеренүләр үзәге) лаек булды. Алар фәнни эшләрен башкалар алдында тәкъдир итте. Чара ахырында катнашучыларга сертификатлар, ә җиңүчеләргә дипломнар тапшырылды.

● Дуслык күпере

# «Ул КФУда гына!»

**Алинә САДЫЙКОВА,** хәбәрче

КФУ кунаклар кабул итәргә, тәҗрибәсе белән уртаклашырга һәм, шул рәвешле, яңа дуслар табарга ярата. Ул дусларның халкыбыз, аның тарихы, татар теле белән кызыксынуларын белү күңелдә аңлатып бетермәслек горурлык хисләре уята.



■ Сулдан уңга: Э.Боспфлуг укытучысы Э.Динмөхәммәтова белән. Ленар Мөхәммәтшин фотосы.

**Элизабет Боспфлуг** – Йельс университетының (АКШ) аспиранты, стажер һәм тарихчы. Ул 2012 елның сентябреннән алып, 2013 елның маена кадәр Казан университетында стажировка үткән. «Мин 9 ай диярлек биредә татар телен өйрәндем. Атнасына 8 сәгать укырга туры килә иде. Җиңел булды, дип әйтмәс идем, әмма укытучыларым ярдәм иттеләр, таяныч булдылар. Нәтиҗәсе: менә сезнең белән татарча сөйләшеп утырам». Америка кунагының чын татарча, бер дә авырсынмыйча сөйләшүен тыңлау җан рәхәте булды. Бу, беренче чиратта, Филология һәм сәнгать институтының тәрҗемә һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлеге укытучыларының хезмәт нәтиҗәсе.

Элизабетның татар теле белән кызыксынуы, аны өйрәнү өчен бик ерактан килүенең сәбәбе дә бар: ул татар зыялылары турында диссертация яза. Йельс университетында архивта да эшләгән. Америкада мондый тема белән кызыксыну, аның фәнни яктан тикшерелүе татарларның көчле потенциалы турында сөйли. «Мин мөселман һәм төрки дөньяларны өйрәнәм. Миңа аларның дини, мәдәни, рухи торышларын, башка мәдәниятләр белән бәйләнешләрен, аларның ничек барлыкка килүен тикшерү бик ошый. Шуңа күрә диссертациямнең темасы да бу юнәлешкә бик якын. Татар зыялылары Советлар Союзында, Төркиядә һәм Европада да булган. Алар турында мәгълүмат туплар өчен, архивта эшләдем. Үз эшемнән канәгать: бик бай материал тупладым, татар телен өйрәндем, күп кешеләр белән аралаштым, таныштым. Хәзер бар булган мәгълүматны энә күзеннән үткәреп, эшләргә һәм эшләргә генә!»

Эзләнү барышында яшь галимә бик күп кызыклы фактларга тап булган: «Латин һәм гарәп графикаларын чагыштырып, татар теленә кайсы күбрәк туры килгәнлеген билгеләү кызык тоелды. Бу минем өчен яңа әйбер иде һәм анда бик күп сорауларым да туды. Алар арасында бәйләнеш эзләргә, шундый катлаулы әйберләрне тикшерергә яратам!» – дип көлеп куйды Элизабет.

Бу кызга сокланмый мөмкин түгел: чит тел үзләштергән арада, шул телдә язылган архивта эшләве, үзенең фәнни юнәлешен шулкадәр яратуы ихтирам хисе уята. Уйлап карасаң, Америкада мөмкинлекләр дә күбрәк шикелле: «КФУ белән Йельс уку йорты арасында аермалар бар һәм алар күп. КФУ – бик матур һәм зур университет, аның бай һәм кызыклы тарихы бар. Йельс – Америкадагы иң яхшы университет, анда материаллар да күп, ә менә татар теле юк! Ул КФУда гына!»

Бу көннәрдә Элизабет кире туган ягына кайтырга әзерләнә. Казан университетында туплаган тәҗрибәсе аңа киләчәктә кирәк булыр дип ышанабыз һәм аңа иҗат уңышлары теләп калабыз.

● Туган тел сагында




Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлеге чит илдә уздырылган конференцияләрдә катнашуын дәвам итә. Татар филологиясе бүлеге мөдире Флера Сәйфулина узган атнада Азәрбайҗанның башкаласында үткән «Төрек һәм ислам дөньясының күренекле мәгърифәтчеләре» исемле симпозиумда булып кайтты.

# «Эстафета безгә бирелде!»

**Алинә САДЫЙКОВА,** хәбәрче

Конференция төрекләрнең талантлы шагыйре, җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче, милли герой дәрәҗәсендәге шәхес – Мехмет Акиф Эрсой истәлегенә багышланды. 1984 елда Төркиянең башкаласы Анкарада аның исемендәге фәлсәфә һәм сәнгать фонды оеша. Әлеге фонд конференцияне үткәрүдә булышлык күрсәтә һәм финанс ягыннан да ярдәм итә. Конференция Бакуда уздырылса да, төп оештыручылар булып, Төркия вәкилләре тора. Чара, Кавказ университеты белән берлектә, 16-18 май көннәрендә үткәрелде. Биредә 12 илдән 104 галим катнашты. Бу конференциянең төп максаты – бөтен төрки халыкларга билгеле булган шәхесләрне таныту; төрки халыклар арасындагы бөек кешеләрне популярлаштыру; галимнәрнең эшчәнлеген, бер-берләре белән аралашуын арттыру.

Конференциянең бик кызык ягы бар: ул һәр елны төрле илдә үткәрелә. Киләсе елга чараны КФУда үткәрергә дигән резолюция кабул ителде. Аңа 11 ил вәкилләре (Азәрбайҗан, Төркия, Кыргызстан, Татарстан, Казахстан, Үзбәкстан, Мисыр, Македония, Сербия, Грузия) кулларын куйды.

Конференция берьюлы ике шәхескә багышлана: Мехмет Эрсой һәм чара үткәрелгән илдәге аңа тиңләшә алырдай шәхескә. Азәрбайҗанлылар шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе Хөсәен Җәвитне тәкъдим иткән. «Эстафета безгә бирелде һәм без дә Мехмет Эрсойга тиң кешене сайлап алырга тиеш булабыз», – дип белдерде Флера Сәйфулина. Бу конференциядә Флера Сәгыйтовна мөселман дөньясына танылган, 20 гасыр башында Төркиядә, Япониядә, Кытайда булып, ислам динен таратып йөргән Себер татары – Габдрәшит Ибраһимов, аның иҗаты һәм эшчәнлеге турында чыгыш ясады.

Чыннан да, эшчәнлек шундый рухта алып барылса, аның нәтиҗәсе дә үзен озак көттермәс. Милли галимнәребезне өйрәнгән вакытта, башка халык галимнәре белән чагыштырып карау бик кызыклы. Юкка гына «һәрнәрсә чагыштыруда беленә» дип әйтмиләр бит!

# Кече университет зур канатлар куя!

**Башы 1нче биттә.**

Укучыларга КФУның танылган галимнәре лекцияләр укый. Аларга, фәнни эш белән шөгыльләнүдән тыш, рәхәтләнеп ял итү мөмкинлеге дә бирелә.

Кече университет базасында ел саен Н.И.Лобачевский ис. Идел буе фәнни конференциясе үтә. Беренче тапкыр ул шәһәр күләмендә 1980 елда уздырыла. Анда Кече университетның 50 укучысы катнаша. 2000 елда конференция Идел буе статусын ала. Катнашучылар чыгыш ясапкына калмый, алдынгы галимнәр белән дә аралаша.

Быел утыз дүртенче чыгарылышта 8-10 сыйныфтан Кече университетны тәмамлаучы 300 укучыга – сертификат, 11 сыйныфны тәмамлаучы 80 укучыга таныклык тапшырылды. Казан федераль университетына кергәндә, Кече университетны тәмамлаучылар өчен бернинди ташламалар да каралмаган. Ләкин бу мөһим фактор түгел. Биредә белем туплау киләчәккә ныклы нигез сала, укучыларны мөстәкыйль тормышка әзерли, университеттагы темпка өйрәтә, иң мөһиме, дөрес һөнәр сайларга ярдәм итә. Кече университет укучылары төрле дәрәҗәдәге олимпиада һәм конференцияләрдә катнашып, зур җиңүләр яулый. Аны тәмамлаган укучылар, югары уку йортына кергәч тә, югалып калмый, ә укуда да, эштә дә, тормышта да зур уңышларга ирешә.

● Бездә кунак бар

# Галәм бит ул, киң бит ул

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

21 май көнне КФУда Россия Фәннәр академиясе галиме Алексей Старобинскийның лекцияләр циклы ачылды. Академик космологиянең хәзерге мәсьәләләре белән таныштырды.





Диана Поварова фотолары

Алексей Старобинский (*фотода*) – физик-теоретик, космология һәм гравитация буенча фәнни эшләр авторы, Россия Фәннәр академиясенең Л.Д.Ландау исемендәге теоретик физика институтының баш фәнни хезмәткәре. Галим А.А.Фридман исемендәге һәм Томалл халыкара премияләре лауреаты, О.Клейн медале белән бүләкләнгән. А.Старобинскийның әлеге лекцияләр циклы өч көн дәвамында барды. Беренче көнне галим КФУның фәнни җәмәгатьчелегенә хәзерге космологиянең стандарт моделе хакында сөйләде. Галәм бик киң һәм күләме буенча чикләнмәгән булырга да мөмкин. Галим үз чыгышында яңа төр материя – караңгы материя һәм караңгы энергия турында да фикерләрен җиткерде. Старобинский лекцияләренең төп максатын болай дип билгеләде: тыңлаучыларны соңгы кырык елда космология өлкәсендә булган үзгәрешләр, яңалыклар, ачышлар белән таныштыру. Галим сүзләренчә, бүген Галәмнең 95 проценты әлегә эксперименталь рәвештә дәлилләнмәгән караңгы материя һәм энергиядән тора. Өстәвенә соңгы 30 ел эчендә Галәм ике тапкырга баеган һәм зурайган икән. Кайбер эксперименталь күзәтүләр аның киңәюен төш һәм атом физикасы вәзгыятьләре белән аңлата. Элек Галәм үсеше ике тарихи чорга бүленеп каралса, бүген галимнәр дүрт чор булганлыгы хакында сөйли.

Кичә, ягъни 22 майда, Алексей Старобинский «Эйнштейн һәм модифицияльләшкән гравитациянең беренчел караңгы энергиясе моделе» дип исемләнгән темага лекция укыды. Цикл ахырында галим Эйнштейн һәм модифицияльләшкән гравитациянең беренчел караңгы энергиясе моделен эксперименталь тикшерүнең хәзерге хәле, күзәтүләрдән чыгып, караңгы энергия үзлеген реконструкцияләү турында сөйләде.

Дуслык күпере

# Уй-максатларыбыз бер!

**Динара МИННЕКАЕВА,**
хәбәрче

15-25 май көннәрендә Филология һәм сәнгать институтында М.Үтәмисев ис. Көнчыгыш-Казахстан дәүләт университеты магистрлары стажировка үтә.



Ленар Мөхәммәтшин фотосы

Уральск шәһәреннән килгән 17 магистр-филолог һәм 8 магистр-тарихчы «Мәдәни диалог: Россия-Казахстан» уртак программасы буенча белем эсти. Бу программа ФСИның тәрҗемә һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлеге, рус филологиясе бүлеге, Тарих институтының татар халкы тарихы һәм тюркология бүлеге укытучылары тарафыннан эшләнгән. Лекцияләрне шулай ук татар филологиясе бүлеге укытучылары да укый. Аерым алганда, алар өчен «Әдәбиятта мәдәни диалог», «Дөнья әдәбиятында көнчыгыш дини мәдәният», «Төрек телләрен укытуда инновацияләр» кебек лекцияләр укылды. Шулай ук магистрлар барлык китапханәләрдә үзләре өчен бай мәгълүмат туплап, диссертация, китап авторлары белән шәхсән танышып, кызыксындырган сорауларына җавап таба алды.

20 май көнне Казахстан магистрлары өчен түгәрәк өстәл дә оештырылды. Алар татар әдәбияты, бәйләнешләр, концептология буенча тәрҗемә һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлеге җитәкчесе, профессор Әлфия Йосыпова, шул ук бүлектән филология фәннәре кандидатлары, доцентлар Мәдинә Саттарова, Фирүзә Сибгаева, Эльвира Динмөхәмәтова, татар филологиясе бүлегеннән XX-XXI гасыр татар әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы мөдире Әлфәт Закирҗанов, филология фәннәре кандидатлары, доцентлар Гөлфия Гайнуллина, Нурфия Йосыповалар белән аралашты. Һәр галимнең чыгышы магистрларда зур кызыксыну уятты. Алар үзләре дә казах филологиясе буенча фикерләрен җиткерде. Әйтик, бездә концептология буенча шактый фәнни хезмәт якланган, ә Казахстан университеты магистрлары бу тема буенча тикшеренү эшләре башлаган гына әле. Укытучылар булачак галимнәргә диссертация язуның кайбер серләрен дә чиште.

Әйтергә кирәк, мондый программа – тәрҗемә һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлегенең беренче тәҗрибәсе. «Әлеге уку йортының казах филологиясе деканы Карлыга Үтәгәнова безгә мөрәҗәгать белән чыккач, бик теләп риза булдык. КФУның Көнчыгыш-Казахстан дәүләт университеты белән хезмәттәшлек итү турындагы меморандумы да бар. 72 сәгатьлек программаны, магистрларның фәнни эш темаларын истә тотып төзедек. Программаны үтәгәч, алар сертифифкат алачак», – дип, мәгълүмат җиткерде тәрҗемә һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлеге мөдире Әлфия Йосыпова.

Магистрлар үзләре өчен Казан университетына килүләренең нинди зур дәрәҗә икәнен кат-кат ассызыклый. «Без Казанда беренче тапкыр. Шәһәрнең гүзәллеген, тарихи яктан гаҗәеп бай икәнен күреп таң калдык. Стажировка дәвамында алган белемнәребезнең бәясе юк! Һәр лекция күзләребез һәм колакларыбыз өчен ләззәт булды. Тик ике атна вакыт бик аз дип уйлыйбыз. Казан федераль университеты галимнәренә биргән белемнәре, үзебезнең уку йорты җитәкчелегенә мондый мөмкинлек тудырганнары өчен, зур рәхмәт сүзләребезне җиткерәбез», – дип фикерләре белән уртаклашты магистрлар. Алар шулай ук бездә китапханәләрнең фәнни әдәбиятка бай икәнлекләрен, үзләре өчен күп яңа мәгълүмат, кызыклы фактларга тап булуларын әйтте. Аларның уку йорты Болон процессына тулысынча күчеп беткән. Дәресләр 50 минут бара, укытучылар белән эшләүдән тыш, мөстәкыйль рәвештә дә фәнни-тикшеренү эшләре башкаралар. Яхшы укыган магистрларга 8-9 мең күләмендә стипендия түләнә, эшкә урнашу мөмкинлеге дә бирелә икән.

Ике як та куйган максатларына ирешкәндер, дип уйлыйм. Казахстан университетлары белән безнең хезмәттәшлек алга таба да шундый нәтиҗәле булса иде.

Фән дөньясында



# Беренче уртак проект

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Шушы көннәрдә Астанада «З.Әхмәтовның фәнни тикшеренүләре һәм хәзерге әдәбият белеменең теоретик проблемалары» темасына багышланган Халыкара фәнни-теоретик конференция узды.

Чара Казахстан фәннәр академиясе академигы, профессор, филология фәннәре докторы Зәки Әхмәтовның (1928-2002) тууына 85 ел булу уңаеннан оештырылды.

Конференция КФУның Филология һәм сәнгать институты һәм Л.Н.Гумилев исемендәге Милли Евразия университеты белән берлектә уздырылган беренче чара булды. Анда Төркия, Кыргызстан һәм Казахстан галимнәре белән беррәттән, КФУ профессорлары Х.Миңнегулов һәм Ф.Сәйфулина да катнаштылар. Шунысы игътибарга лаек: бу конференцияне уздыру идеясе 2012 елның октябрь аенда КФУда туа. «Көз көне бездә зур масштаблы халыкара фәнни конференция булды. Шул вакытта без Казахстанның Л.Н.Гумилев исемендәге Милли Евразия университеты белән бәйләнешкә кердек. Бу уку йортыннан безнең конфренциядә бер төркем галимнәр катнашты. Шул вакытта без, алар белән сөйләшеп, кафедралар арасында (бездә татар әдәбияты тарихы кафедрасы, аларда казах әдәбияты тарихы кафедрасы бар) бәйләнешләр урнаштырырга кирәк дигән уртак фикергә килдек. Шушы сөйләшү нәтиҗәсендә, 3 май көнне Астанада ике кафедраның уртак конференциясе узды», – дип, фикерләре белән уртаклашты татар филологиясе бүлеге мөдире Флера Сәйфулина.

Чарада КФУ делегациясе 13 доклад белән катнашты. Каралган темалар төрле: әдәбият теориясе, әдәбият тарихы, төрки халыклар әдәбиятының үсешенә бәйле мәсьәләләр һәм башкалар. Конференция турында йомгак ясап, Флера Сәйфулина: «Быел көзгә бездә уртак конференция оештырырга дип килештек. Аспирант, магистрлар алышу программалары, стажировкалар үтү мәсьәләләре каралды. Безгә хәзер бәйләнешләрне өзмичә, аларны тагын да ныгытырга, уртак проектлар эшләргә кирәк, дигән уйлар белән кайттык», – диде.

Максат-бурычлар куелган, шартлар тудырылган – Л.Н.Гумилев исемендәге Милли Евразия университеты вәкилләрен көтәсе генә кала.

Пионерия көне

# Пионерлар булып калабыз!

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

«Пионерлар» сүзен ишетүгә, кызыл галстуклы, пилоткалы бер рәткә тезелгән балалар күз алдына килеп баса. Чын пионер, укучы ролен генә түгел, хәтта җитәкче, вожатый да булырга, тәртипле, матур сыйфатларга, эш-гамәлләргә дә ия булырга тиеш.

Балалар оешмасы – иҗтимагый тормыш мәктәбе ул. Анда катнашу буш вакытны файдалы һәм кызыклы итеп үткәрергә, шәхес буларак танылырга ярдәм итә. Бүген инде безнең буын пионерларның кем икәнлеген дә белми.

Пионерия көне элек тә шундый кызык, күңелле булганмы икән? Әлеге сорауны мин мәктәбебездә озак еллар буе директор булып эшләгән, мәгариф өлкәсендәге уңышлары өчен Татарстанның фән һәм мәгариф, авыл хуҗалыгы министрлыгы грамоталары белән бүләкләнгән, Россия Федерациясенең мактаулы укытучысы, мәктәптә укыган елларында дружина советы председателе булган Мәймүнә Хафиз кызы Хайретдиновага бирдем.

**– Мәймүнә апа, сез үзегезнең пионерлыкка кабул ителү көнегезне хәтерлисезме?**

– Без бала чакта май аенда пионерлар көнен билгеләп үтә идек. 9 яшь тулгач, өченче сыйныфта укыганда, 19 майда, дружина сборында тантаналы рәвештә пионерга кабул итү тантанасы уза иде. Без барыбыз да пионерга кердек. Өч звенога бүлендек, алар бер отряд тәшкил итте. Һәр отрядның үз флагы, девизы, үз барабанчысы була иде. Отряд сборында, өлкән пионервожатый җитәкчелегендә, отряд советын һәм аның председателен сайлый идек (Ул вакытта әле җыелыш түгел – сбор, рәис түгел – председатель). Иң тырыш, актив укучы, башкаларга карата ярдәмчел булганга, оештыру сәләтләрем һәм «командный» тавышым аерылып торганга, мине отряд советы председателе итеп сайлап та куйдылар. Менә шулай пионер «карьерам» башланып китте. 7 сыйныфта укыганда инде дружина советы председателе идем. Һәр отрядтан иң актив укучыларны Киев, Анапа, Сочи кебек ерак шәһәрләргә экскурсиягә җибәрәләр иде. Миңа да, иң актив укучы буларак, Киев шәһәренә бару мөмкинлеге насыйп булды. Ай саен дружина әгъзалары оешма җитәкчеләренә хисап биреп, төрле биеклекләргә омтыла идек. Иң күңелле мизгелләр, әлбәттә, учак ягулар иде. Кырга чыгып, бөтен дружина белән учак тирәли йолдыз формасы ясап җырлый, рәхәтләнеп ял итә идек. Әле дә хәтеремдә...



Остазым пионерлыкның гел уңай якларын гына искә ала. «Сугыштан соңгы авыр елларда, ул балалар тормышына бер ямь, җылылык кертә, бердәмлек, дуслык хисе уята иде. Сборлар, артта калган укучыларга ярдәм итү, өмәләргә йөрү, урак өстендә ярыша-ярыша башак җыю, өлкәннәргә, мохтаҗларга булышу, авыруларга ярдәм күрсәтү, концертларда, мәктәптә кичәләрдә катнашу һ.б. Болар барысы да мораль канәгатьлек хисе тудыра иде».

Заманында «октябрят» һәм «пионер» дип йөртелгән бу исемнәр хәзер «эзтабарлар» һәм «варислар»га алышынды. Ләкин аларның эш юнәлешләре, максатлары бертөрле. «Мин, үз чиратымда, варисларның шушы герой-пионерлар кебек курку белмәс, Ватанны яратучы патриот булып үсүләрен телим», – дип тәмамлады сүзен Мәймүнә апа.

Пионерия көне гомер-гомергә безнең әти-әниләрнең, әбибабаларның күңелләрендә иң яраткан, иң истә кала торган бәйрәмнәрнең берсе булып калыр.

**• Алар бездә укыган**

# «Һөнәрем буенча эшлим»

**Кадрия ХӘСӘНОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Кызлар, аның гаҗәеп матур тавышына сокланып, «Күпме күзләр күреп онытылган», «Кем булыйм икән сиңа», «Яшәрми кая барасың», «Кайтчы, иркәм» кебек җырларын үлә-бетә тыңлый. Фәнил төрле буын вәкилләренең күңелләрен күтәреп, концертлар алып бара, мәҗлесләрдә, туйларда ул – халык яратып өлгергән тамада! Ә кечкенә вакытта футболист булырга хыялланган. Безнең уку йортының чыгарылыш студенты да. Тагын кем ул Фәнил Вакказов? Нинди уйлар белән яши? Бу сорауларга җавапны интервьюны укып белерсез!



**Досье:**
Тулы исеме: **Фәнил Әюп улы Вакказов**
Туган көне: **1 октябрь, 1984 ел**
Туган ягы: **Саба районының Мәртен авылында туган, Байлар Сабасында үскән.**

**- Әйдә, фамилияңнән башлыйк әле, Фәнил. Нәрсәне аңлата ул, беләсеңме?**

- Фамилиям «Ваккәс» исеменнән ясалган. Бу исемне игезәк сыңарына куша торган булганнар. Минем бабамның әтисе шул исемне йөрткән.

**- Гаиләң белән таныштырып үт әле?**

- Әтием Әюп «Сабагаз» оешмасында эшли. Гармунда уйнап җырларга һәм оныгын күкрәгенә салып йоклатырга ярата (*елмая - К.Х.*). Әнием Лилия, Саба үзәк шифаханәсендә эшли. Ул тегү-чигү эшен һәм безнең кунакка кайтканны ярата. Сеңлем - Гөлназ, «Сбербанк»та эшли, әлегә кияүдә түгел. Ул үзенең эшен һәм волейбол уйнарга ярата, чөнки без кайтканда, я эштә, я волейболда була.

**- Үзең дә гаилә корып җибәрдең, тормыш иптәшең, балагыз белән дә таныштыр әле?**

- Гаиләмдә өч кеше: мин, хатыным Гөлназ һәм улыбыз Нурбәк. Нурбәк исемен үзем сайладым. Моннан ун еллар чамасы элек Рабит Батулланың улы Нурбәк Батулла белән танышуга ук, малаем туса, Нурбәк кушам, дип әйтеп куйган идем. Ул егетне мин үземнең дустым дип саныйм, аның талантына, үз-үзен тотышына, тәрбиясенә карап сокланам, аны белүем белән горурланам. Бу исем хатыныма да бик ошый. Хатыным, һөнәре буенча, администрация хезмәткәре.

**- Барлык осталыкларыңнан чыгып, синең һөнәреңне ничек атыйк икән?**

- Белемем буенча, мин яртылаш филолог, яртылаш тарихчы, чөнки Казан университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетын тәмамладым. Үземне, һөнәрем буенча, алып баручы, дип тоям. Кая эшлисең, дип сораган бөтен кешегә дә һөнәрем буенча эшлим дип әйтәм, чөнки мин тел белгече һәм телем белән акча эшлим (*елмая - К.Х.*).

**- Синең бик матур җырларың да бар бит. Клип төшерергә, җырчы булып китәргә уең юкмы?**

- Киләчәктә берәр җырга булса да клип төшерү теләге бар, яшермим. Җырчы булырга уйлаганым юк, чөнки эстраданы болай да минем шикелле үзешчәннәр басып бетерде инде. Бу дөрес хәл түгел, вакыт моны төзәтер, дип саныйм. Җырчы булыр өчен, профессиональ белем алырга кирәк, минемчә.

**- Бәйрәмнәр алып баручыга менә шундый сорау: күңел ачу, бәйрәмнәргә кеше тормышында күпме урын бирелергә тиеш?**

- Кеше тормышында елмаю һәрвакыт булырга тиеш, чөнки ансыз яшәү мөмкин түгел! Әйләнә-тирәдәгеләрнең сиңа булган мөнәсәбәте дә бит күбрәк елмаю аша күренә. Ә зуррак бәйрәмнәр гадәти кеше тормышында ярты елга бер булырга тиештер, дип саныйм, чөнки атна саен бәйрәмгә йөрү ардырырга һәм кесә төбен дә саетырга мөмкин. Минем тормыш инде, үзегез беләсез, гел бәйрәмнән генә тора. Эшем шундый бит.

**- Бу тормышта чын мәгънәсендә сине борчыган проблемалар?**

- Мине берничә мәсьәлә бик борчый. Мәсәлән, туган телебез белән ни булыр, балаларыбыз безнең шикелле рәхәтләнеп, авыз тутырып, татарча сөйләшә алырмы? Бу хәл ителә торган проблема! Аның чишелешен һәр кеше үз гаиләсеннән башларга тиеш, безнең гаиләдә дәүләт теле булып татар теле санала. Мине борчыган тагын бер мәсьәлә - дәүләт белән идарә итү системасының үтә күренмәле булмавы. Чыннан да, без үзебезнең салымнарның нәрсәгә тотылганын да белмибез бит, шуңа халыкның салым түлисе дә килми. Бюджет акчасының күпме һәм нәрсәгә тотылганын без белеп торырга тиеш. Көн саен интернетта шундый хәбәрләр укыйсың, шартлы рәвештә әйтәм, бу күперне салырга фәлән кадәр акча - 50 миллион булсын, бүленеп бирелгән, ә эш бары 10 миллионга гына башкарылган. Ә калган 40 миллион кая киткәнен син дә, мин дә – бер кеше дә белми бит!

**- Киләчәккә булган глобаль планнарың белән уртаклаш әле?**

- Глобаль план бер генә ул - кеше көлдермичә, кешеләргә кирәк булып, лаеклы гына тормыш юлы буйлап барырга иде.

**- Әңгәмәң өчен рәхмәт, киләчәктә уңышлар, гаиләңә саулык телим, Фәнил!**

**• Студент эш эзли**

# Алдакчы игъланнар

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

2 курсны тәмамлагач, уйланып калдым: озаклмый миңа 20 яшь тула, ә мин һаман әти-әни җилкәсендә «утырам»! Бу хәлне кичекмәстән үзгәртергә кирәк иде, шуңа күрә җәйгә эшкә урнашырга булдым.



## Беренче коймак

Эш эзләүне газетадагы һәм интернеттагы игъланнарны караштырудан башладым. Минем игътибарны «курьер» дигән вакансия җәлеп итте. Эш тәҗрибәсе кирәкми, диплом да таләп итмиләр. Әйтерсең, мине генә көтеп торалар! Күрсәтелгән телефон номерына шалтыраттым. Ягымлы хатын-кыз тавышы кичке сәгать дүрткә офисларына әңгәмәгә чакырды.

Офис ишеген ачып кергәч, минем кебек эш эзләүчеләр шактый булуы ачыкланды. Бөтенебезгә анкета тутырырга куштылар. Үзен оешманың директоры дип таныштырган ир кеше ике төрле вакансия барлыгын әйтте: курьер һәм курьер-консультант. Гадәти курьер оешманың документларын төрле фирмаларга таратып йөрергә тиеш. Акчасын көн ахырында түлиләр, 850 сум. Ә консультант дигәне, документларны өләшүдән тыш, оешманың эше турында сөйләргә, төрле кәгазьләр тутырырга тиеш. Акчасы да күбрәк – 1050 сум. Ризалаштым. Икенче көнне сәгать иртәнге 9да офиста булырга кирәк. Мин килгәндә, анда инде 20гә якын кеше утыра иде. Бөтенесе диярлек студентлар. Аерым төркемнәргә бүлеп, җитәкче билгеләделәр. Көне буе аларның эшләрен карап, «һөнәрнең» асылына төшенергә тиеш идек. Әмма эшнең исеме җисеменә бөтенләй туры килмәгәне соңрак кына ачыкланды.

Нәрсә беләндер тутырылган зур-зур сумкаларны алып эшкә киттек. «Әллә шуның кадәр документ микән монда? Бик каты эшли болар. Билсез каласың бит моны йөртә-йөртә», – дип уйлап куйдым. Казанның бер сәүдә үзәгенә килгәч: «Менә карап торыгыз, хәзер мин сезгә ничек эшләргә икәнен күрсәтәм», – диде җитәкчебез. Һәм сумкадан төрле китаплар чыгарып, шуларны тәкъдим итә башлады! Кибеттән чыгуга, «укытучыма» монда эшләргә теләмәгәнемне әйттем һәм китәргә булдым.

## Тагын алдадылар!

Беренче коймак төерле була, дигән сүзләр белән үземне тынычландырырга тырыштым һәм яңадан белдерүләр карарга тотындым. «Промоутер вакансиясенә 18 яшьлек кыз кирәк», – дигән игъланга күзем төште. Шалтыраткач, җавап биргән егет исемемне һәм телефон номерымны сорап: «Иртәгә иртәнге сәгать 10да хәбәрләшербез», – диде. Тик, билгеләнгән вакыт килеп җиткәч, бернинди шалтыратучы да булмады. Аптырагач, үзем белешергә булдым. «Иртәгә шалтыратырбыз», – дип җавап кайтардылар. Шундый ук хәл берничә көн рәттән кабатланды. Монда да алдадылар, дип уйлап куйдым да, яңадан эш эзләргә керештем.

## Бирәм дигән колына...

Хәзер инде бөтен белдерүләр миндә шик уята башлады. Гел алдарлар кебек. Әмма интернет сайтларының берсендә бик кызыклы тәкъдимне күреп, тагын бер талпынып карарга булдым. Башкалада эшли торган агентлык «промоутер» һәм «интервьюер» (социологик сораштырулар үткәрә торган кеше) вакансияләренә студентлар эзли икән. Агентлыкта мине бер апа каршы алды һәм сораулар язылган кәгазьләрне тутырырга кушты. Бөтен сорауга җавап биргәч, анкетамны җитәкчегә бирделәр. Хәзер тагын: «Иртәгә хәбәрләшербез», – диярләр инде болар, дип уйлап куюым булды, янbackыма бер менеджер килеп утырды. Ул вакансияләрнең асылын аңлатты һәм хәзерге вакытта бара торган акцияләр турында сөйләде. Мин үземә ошаган вариантны сайлап, бүген үк эшкә керешә алам икән. Интервьюер вакансиясен сайладым. Эш тәртибе мондыйрак: акция вакытында, мин зур сәүдә үзәге янында торып, кешеләргә анкетадагы сорауларны бирергә тиешмен. Иң мөһиме – җавап бирүчеләрдән телефон номерларын алып калырга кирәк. Ник дигәндә, анкеталарны тикшерү өчен, Мәскәүгә җибәрәләр, анда, күрсәтелгән номерлар буенча шалтыратып, әлеге кешенең сораштыруда катнашканмы, юкмы икәнен сорыйлар. Шуңа күрә җавапны һавадан алып язып куеп булмый!

Шул көннән башлап, эшли дә башладым. Әлбәттә, башта кыенрак иде. Чөнки бөтен кеше ашыга, берәүләр җавап бирергә теләми, икенчеләр бөтенләй сүгенеп китә. Тик араларында бик теләп, елмаеп җавап бирүчеләр дә табылды. Беренче эш көнендә мин 100гә якын анкета тутырдым. Хәзер инде 200-300не тутырган чаклары да бар.

Акчасы бик күп булмаса да, студент өчен җитәрлек. Параллель рәвештә ике акциядә эшләү мөмкинлеге дә бар. Ә баштарак кичергән уңышсызлыкларга мин рәхмәтле, чөнки бу үзенә күрә бер тәҗрибә булды.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.